**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советы**

**КАРАР №16**

Бәйрәкәтамак ав. 15.11.2022

Бәйрәкәтамак авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен
даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның,
җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының,
муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе
һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 13 декабрендәге 2018 елның 28 мартындагы«Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» 182 санлы Татарстан Республикасында «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы контроль-хисап органнары рәисләренең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары хакында»гы 1222 санлы, Татарстан Республикасы министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 санлы Татарстан Республикасында «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы контроль-хисап органнары рәисләренең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары хакында»гы 881 санлы карары нигезендә, Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 маендагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 10 санлы карары белән расланган, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының айлык акчалата хезмәт хакының күләмен 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга.
2. Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 маендагы «Татарстан

Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 10 санлы карары белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2022 елның 1 октябреннән арттырырга.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладı күләмен 1,04 тапкырга индексацияләү һәм аны 11 958,00 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча куярга: www.jutaza.tatar.ru

5. Бу карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарны контрольдә тотуны үз өстемә алам

Бәйрәкәтамак
авыл җирлеге башлыгы Ф.В.Әхмәтов